КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 8 апрель г.Казань № 239

2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында яшь геологларның X республика ачык кыр олимпиадасын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 11 июленнән 17 июленә кадәр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында «Солнечный» балалар сәламәтләндерү лагере базасында яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасын (алга таба – олимпиада) уздырырга.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024 елда яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм уздыру чаралары планын (алга таба – план);

2024 елда яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасының оештыру комитеты составын.

3. Олимпиаданың оештыру комитетына:

план чараларының үтәлешен яраштырырга;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән расланган «Балаларга һәм яшьләргә тәрбия һәм белем бирүне, аларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.4.3648-20 санитария кагыйдәләре, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы карары белән расланган «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СанПиН 2.3/2.4.3590-20 санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә олимпиада уздыруны тәэмин итәргә;

2024 елда олимпиада әзерләү һәм уздыру буенча чараларның эреләтелгән смета исәп-хисабын расларга.

4. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте, «Нефтеконсорциум-МНК» акционерлык җәмгыяте, кече нефть компанияләренең 2024 елда яшь геологларның мәктәп командаларын әзерләүдә һәм яшь геологларның

X Республика ачык кыр олимпиадасын уздыруда һәрьяклап ярдәм күрсәтү һәм аларны финанслау турындагы тәкъдимнәрен (карарга теркәлә) кабул итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте, «Нефтеконсорциум-МНК» акционерлык җәмгыяте һәм Татарстан Республикасының кече нефть компанияләре белән олимпиада уздыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек оештырырга;

2024 елда яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасы турындагы нигезләмәне эшләргә һәм расларга.

6. Республика башкарма хакимияте органнарына, шулай ук олимпиада уздыруга җәлеп ителгән башка органнарга һәм оешмаларга план чараларын билгеләнгән срокларда үтәүне тәэмин итәргә.

7. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында олимпиада уздыру турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

8. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институтына олимпиада белән фәнни-методик җитәкчелек итүне;

Әлмәт муниципаль районының башкарма комитетына:

оештыру комитетына олимпиаданы әзерләүдә һәм уздыруда ярдәм күрсәтүне;

уздыру объектларында һәм олимпиадада катнашучыларның яшәү урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

олимпиада уздыру объектларын һәм олимпиадада катнашучыларның яшәү урыннарын әзерләүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында яшь геологларның IX Республика ачык кыр олимпиадасын уздыру турында» 2023 ел, 17 март, 262 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабитнетының «2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында яшь геологларның IX Республика ачык кыр олимпиадасын уздыру турында» 2023 ел, 17 март, 262 нче карарына теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү хакында» 2023 ел, 11 апрель, 441 нче.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 8 апрель, 239 нчы
карары белән расланды

2024 елда яшь геологларның IX республика ачык кыр олимпиадасына әзерләү һәм аны уздыру буенча чаралар планы

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы башкаручылар | Башкарудашчылар | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | «Солнечный» балаларны савыктыру лагере базасында, шәһәр яны стационар лагерьлары эшенә куела торган таләпләрне исәпкә алып, кирәкле әзерлек эшләрен башкару һәм шәһәр яны лагеренең санитария-эпидемиология таләпләренә («Балаларга һәм яшьләргә тәрбия һәм белем бирүне, аларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.4.3648-20 санитария кагыйдәләре) туры килүен билгели торган санитария-эпидемиология бәяләмәсен алу, «Солнечный» балалар савыктыру лагеренең бердәм радиотапшырулар системасын оештыру эшләрен башкару | яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты), В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 2024 елның 11 июленә кадәр |
| 2. | Түбәндәгеләрне раслау:<br>яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасы турындагы нигезләмәне; | оештыру комитеты | «Казан (Идел буе) федераль университеты» | 2024 елның 11 маена кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасының (алга таба – олимпиада) эшче төркеме составын;<br>суд коллегиясе составы | | югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | |
| 3. | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе каршындагы яшь геолог мәктәбенең уку-укыту барышын оештыру, олимпиадада катнашырга теләк белдергән мәгариф оешмалары базасында түгәрәкләр | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | оештыру комитеты | ел дәвамында |
| 4. | Ярышларның кыр маршрутларын, планлаштырылган машиналар куеп тору урыннарын эшләү һәм оештыру, аларны Куллanучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән килештерү | оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы | 2024 елның 1 июленә кадәр |
| 5. | «Солнечный» балаларны савыктыру лагере һәм кыр маршрутлары, олимпиада уздырганда җәлеп ителгән машиналар куеп тору урыннары базасында дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация, талпанга каршы (акарицид белән) эшкәртү эшләрен башкаруны тәэмин итү һәм аларны үткәрүне контрольдә тоту | оештыру комитеты, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 2024 елның 11 июленә кадәр |
| 6. | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесеннән волонтерлар | оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль | | 2024 елның 11 июленә кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | һәм вожатыйлар сайлап алу һәм әзерләү | дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | | |
| 7. | Минераллар, тау токымнары, палеонтология коллекцияләре, кисемнәр төзү буенча уку-укыту геологик карталарын әзерләү | оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | | 2024 елның 11 июленә кадәр |
| 8. | Олимпиада үткәрү өчен кирәкле приборлар һәм аппаратура белән тәэмин итү | оештыру комитеты | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) | 2024 елның 11 июленә кадәр |
| 9. | Гамәлдәге санитария-эпидемиология таләпләре нигезендә олимпиада уздыру урыннарында катнашучыларны кабул итүне, урнаштыруны, аларның яшәвен оештыру.<br>Профилактика һәм дезинфекция чараларын үткәрү буенча санитария-эпидемиология таләпләрен исәпкә алып, олимпиадада катнашучыларның туклануын оештыру, шул исәптән олимпиада башлану алдыннан «Солнечный» балалар савыктыру лагереның азык-төлек цехы хезмәткәрләрендә эчәк инфекцияләренең норовирус, ротавирус һәм башка вируслар тудыручылары булу-булмавын тикшерү (эшкә чыгу көненә кадәр кимендә өч календарь көн алдан).<br>Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше | оештыру комитеты, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2024 – 17.07.2024 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән сатыла торган ризыклар ассортиментын (меню) килештерү | | | |
| 10. | Олимпиада уздыруны IT-инфраструктура объектлары белән мәгълүмати-технологик тәэмин итү, шул исәптән олимпиада штабын оештыру, оештыру техникасы һәм компьютерлар белән комплектлау | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) | оештыру комитеты | 11.07.2024 – 17.07.2024 |
| 11. | Олимпиаданың мәдәни һәм спорт программаларын оештыру, шул исәптән:<br>олимпиаданы ачу һәм ябу сценарийларын эшләү һәм аларны гамәлгә ашыру;<br>олимпиада уза торган көннәрдә мәдәни-ял итү программасын гамәлгә ашыру | оештыру комитеты | | 11.07.2024 – 17.07.2024 |
| 12. | Олимпиада уздырыла торган урыннарда җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итүдә оештыручыга ярдәм күрсәтү | оештыру комитеты, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2024 – 17.07.2024 |
| 13. | Яшәү, катнашучыларны тукландыру һәм олимпиада уздыру урыннарында санитария-эпидемиология таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү | оештыру комитеты | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2024 – 17.07.2024 |
| 14. | Олимпиаданы әзерләү һәм үткәрү чорында оештыручыга санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык | әзерлек чорында – 2024 елның |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча) | җәмгыяте (килешү буенча) | 11 июленә кадәр |
| 15. | Олимпиада ярышларын үткәрү һәм катнашучылар яшәү урыннарда янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү | оештыру комитеты, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча) | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2024 – 17.07.2024 |
| 16. | Олимпиада уздыруга медицина ярдәме күрсәтү, шул исәптән:<br>олимпиада уздырыла торган урында тәүлек буе эшли торган медицина пунктын оештыру;<br>олимпиада уздырыла торган урыннарда, шулай ук күчмә ярышлар үткәрелә торган урыннарда ашыгыч медицина ярдәме бригадасының кизү торуын оештыру | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) | 11.07.2024 – 17.07.2024 |
| 17. | Республика массакүләм мәгълүмат чараларында олимпиада уздыруны яктыртуны тәэмин итү | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | оештыру комитеты | 11.07.2024 – 17.07.2024 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 8 апрель, 239 нчы
карары белән расланды

2024 елда яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасы
оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Мəганов Наил<br>Өлфəт улы | В.Д.Шашин исемендəге «Татнефть» гавами акционер җəмгыяте генераль директоры, оештыру комитеты рəистəше (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур<br>Гəрəй улы | Татарстан Республикасы мəгариф һəм фəн министры, оештыру комитеты рəистəше |

Оештыру комитеты əгъзалары:

| | |
|---|---|
| Əфлəтунов Ринат<br>Рəкыйп улы | В.Д.Шашин исемендəге «Татнефть» гавами акционерлык җəмгыяте генераль директоры урынбасары – баш геолог (килешү буенча) |
| Əюпова Ирада<br>Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мəдəният министры |
| Бачков Альберт<br>Петрович | В.Д.Шашин исемендəге «Татнефть» гавами акционерлык җəмгыятенең нефть һəм газ ятмаларының геология идарəсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гаврилов Евгений<br>Владимирович | В.Д.Шашин исемендəге «Татнефть» гавами акционерлык җəмгыятенең Персонал белəн эшлəү идарəсенең корпоратив мəдəниятне һəм яшьлəр сəясəтен үстерү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Галиев Ренат<br>Марат улы | Татарстан Республикасы Рəисе ярдəмчесе (килешү буенча) |
| Гатиятуллин Рамил<br>Нəкыйп улы | В.Д.Шашин исемендəге «Татнефть» гавами акционерлык җəмгыятенең Татар геологик разведка идарəсе башлыгы (килешү буенча) |
| Глазков Андрей<br>Александрович | В.Д.Шашин исемендəге «Татнефть» гавами акционерлык җəмгыятенең Персонал белəн эшлəү идарəсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ермолаев Андрей Сергеевич | корпоратив культураны үстерү төркеме, Корпоратив культураны үстерү үзәге, Корпоратив университет, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Бизнеска хезмәт күрсәтү үзәге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Исламова Гөлнара Илдар кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры |
| Кадәмов Ирек Илгиз улы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Минһаҗев Рафаэль Рафис улы | «Нефтеконсорциум-МНК» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнуллин Марсель Мансур улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Мөхәммәдиев Рөстәм Нәбиулла улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының социаль үсеш буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Мөхәммәтшин Ренат Нурислам улы | Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Нагуманов Тимур Дмитриевич | Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Нургалиев Данис Карлович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе проректоры (килешү буенча) |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сатретдинов Дамир Рөстәм улы | Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Терехин Андрей Анатольевич | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шәрәфетдинова Юлия Юрьевна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институтының геофизика һәм геомәгълүмат технологияләре кафедрасы инженеры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 8 апрель, 239 нчы
карарына кушымта

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте, «Нефтеконсорциум-МНК» акционерлык җәмгыяте, кече нефть компанияләренең 2024 елда яшь геологларның мәктәп командаларын әзерләүдә һәм яшь геологларның X Республика ачык кыр олимпиадасын уздыруда һәрьяклап ярдәм күрсәтү һәм аларны финанслау турында тәкъдимнәре

| Т/с | Предприятие исеме | Кертем суммасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ | 14 000 000,0 |
| 2. | «РИТЭК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «ТатРИТЭКнефть» территориаль-җитештерү предприятиесе | 480 000,0 |
| 3. | «Татнефтеотдача» АҖ | 295 000,0 |
| 4. | «Кара Алтын» предприятиесе» ЯАҖ | 250 000,0 |
| 5. | «Татех» АҖ | 205 000,0 |
| 6. | «МНКТ» ҖЧҖ | 230 000,0 |
| 7. | «Татойлгаз» АҖ | 215 000,0 |
| 8. | «Шешмаойл» АҖ | 200 000,0 |
| 9. | «Татнефтепром – Зюзеевнефть» АҖ | 155 000,0 |
| 10. | «СМП-Нефтегаз» АҖ | 125 000,0 |
| 11. | «Охтинойл» ЯАҖ | 135 000,0 |
| 12. | «Алойл» ЯАҖ | 110 000,0 |
| 13. | «Татнефтепром» АҖ | 120 000,0 |
| 14. | «Камскойл» ҖЧҖ | 15 000,0 |
| 15. | «Троицкнефть» ЯАҖ | 115 000,0 |
| 16. | «Иделойл» АҖ | 100 000,0 |
| 17. | «НК-Геология» ҖЧҖ | 80 000,0 |
| 18. | «Булгарнефть» АҖ | 65 000,0 |
| 19. | «Трансойл» ҖЧҖ | 70 000,0 |
| 20. | «Геология» АҖ | 55 000,0 |
| 21. | «ГРИЦ» АҖ | 60 000,0 |
| 22. | «Геотех» АҖ | 45 000,0 |
| 23. | «Меллянефть» АҖ | 25 000,0 |
| 24. | «Кондурчанефть» АҖ | 25 000,0 |
| 25. | «Карбон-Ойл» ҖЧҖ | 35 000,0 |
| 26. | «Акмай» АҖ | 5 000,0 |
| 27. | «Алабуганефть» АҖ | 5 000,0 |
| Барлыгы | | 17 220 000,0 |